| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЖШЕРУСАКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ УРСАК АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 08 мае Олы Урсак ав. №71

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 октябрендәге 27 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 31 октябрендәге 27 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 9 статьяның 4 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 12 абзац өстәргә:

««Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр төзи, аларга федераль бюджет акчалары (дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) капитал салуларны финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы булып тора.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http:/ brusakov-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы

буенча Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Олы Урсак авыл җирлеге Башлыгы Г.А.Зиннәтуллин